ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 33 от «26» 01 2024 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районы җирлекара
күмү урыннарында җирләү буенча
гарантияләнгән исемлек
нигезендә хезмәт күрсәтү бәясен
раслау турында

«Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 нче гыйнварындагы 8-ФЗ санлы Федераль законның 9 статьясының 3 пункты һәм 12 статьясының 3 пункты (үзгәрешләр һәм өстәмәләрне исәпкә алып), «Татарстан Республикасында «Күмү һәм җирләү эше турында» Федераль законны тормышка ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 нчы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты

к а р а р б и р ә:

1. Мамадыш муниципаль районы җирлекара күмү урыннарында җирләү буенча гарантияле исемлек нигезендә хезмәт күрсәтү бәясен 1 нче һәм 2 нче кушымталар нигезендә 8370,2 сум күләмендә билгеләргә һәм 2024 нче елның 1 февраленнән гамәлгә кертергә.

2. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында җирләү буенча хезмәт күрсәтүләрнең бәясен, авыл җирлекләрен дә кертеп, 2024 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлегенә таянып, әлеге карарга 3 нче кушымтада билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 30 гыйнварындагы 21 номерлы карарын гамәлдән чыгарырга.

4. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары А.Х. Әгъләмовка йөкләргә.

Җитәкче О.Н.Павлов

000012197

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Башкарма комитетының
26. 01 2024 ел , № 33 карарына
1 нче кушымта

2024 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы җирлекара күмү урыннарында җирләү буенча гарантияле исемлек нигезендә тормыш иптәше, якын туганнары, законлы вәкиле үлгән (һәлак булган) очракта, хезмәт күрсәтү бәясе

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда). |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен документлар әзерләү | 0 |
| 2. Гүргә иңдерүгә кабер такталары, табут һәм башка предметлар бирүгә һәм китерүгә | 3850,33 |
| 3. Мәетне (мәет калдыкларын) зиратка алып килүгә | 1003,26 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3516,61 |
| Барлыгы | 8370,2 |

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Башкарма комитетының
26. 01 2024 ел , № 33 карарына
2 нче кушымта

2024 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы җирлекара күмү урыннарында җирләү буенча гарантияле исемлек нигезендә, тормыш иптәше, якын туганнары, законлы вәкиле булмаган очракта, хезмәт күрсәтү бәясе

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда). |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен документлар әзерләү | 0 |
| 2. Мәетне киендерү, кәфенләү | 1194,54 |
| 3.Гүргә индерүгә кабер такталары, табут һәм башка предметлар бирүгә һәм китерүгә | 2765,12 |
| 4.Мәетне (мәет калдыкларын) зиратка алып килүгә | 1023,57 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3386,97 |
| Барлыгы | 8370,2 |

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Башкарма комитетының
26. 01 2024 ел , №33 карарына
3 нче кушымта

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районында, авыл җирлекләрен дә кертеп, 2024 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлегенә таянып, җирләү буенча хезмәт күрсәтүләрнең бәясе

| № /б | Муниципаль берәмлек, авыл җирлекләре исеме | Күмү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенә таянып, бәясе, сумнарда |
|---|---|---|
| 1 | Албай авыл җирлеге | 8370,2 |
| 2 | Югары Ушма авыл җирлеге | |
| 3 | Дүсмәт авыл җирлеге | |
| 4 | Ишки авыл җирлеге | |
| 5 | Катмыш авыл җирлеге | |
| 6 | Көмешкүл авыл җирлеге | |
| 7 | Келәүш авыл җирлеге | |
| 8 | Красная Горка авыл җирлеге | |
| 9 | Көек-Ерыкса авыл җирлеге | |
| 10 | Кече Кирмән авыл җирлеге | |
| 11 | Түбән Ушма авыл җирлеге | |
| 12 | Түбән Сон авыл җирлеге | |
| 13 | Түбән Тәкәнеш авыл җирлеге | |
| 14 | Түбән Шүләңгер авыл җирлеге | |
| 15 | Никифорово авыл җирлеге | |
| 16 | Олыяз авыл җирлеге | |
| 17 | Омар авыл җирлеге | |
| 18 | Отарка авыл җирлеге | |
| 19 | Соколка авыл җирлеге | |
| 20 | Урта Кирмән авыл җирлеге | |
| 21 | Сон авыл җирлеге | |
| 22 | Тауиле авыл җирлеге | |
| 23 | Уразбахты авыл җирлеге | |
| 24 | Урманчы авыл җирлеге | |
| 25 | Усали авыл җирлеге | |
| 26 | Шәдче авыл җирлеге | |
| 27 | Шәмәк авыл җирлеге | |
| 28 | Яке авыл җирлеге | |
| 29 | Мамадыш шәһәре | |